АЛЛАҺЫНЫҢ СЕЗНЕ ЯРАТУЫ ТУРЫНДАГЫ ГАДИ ХАКЫЙКАТЬ

# ӘЙТ АЛАРГА: МИН АЛАРНЫ ЯРАТАМ

ДЖОЙС МАЙЕР

ӘЙТ АЛАРГА:

# *Мин аларны яратам*

ӘЙТ АЛАРГА:

# *Мин аларны яратам*

*Алланы Тәгалә сезне ярата –*
бу гади хакыйкать

# ДЖОЙС МАЙЕР

Изге Язмадан алынган өзекләр, аерым билге белән күрсәтелмәгән очракта, Изге Язманың татар теленә тәрҗемәсеннән алынган («Изге Язма. Тәүрат, Зәбур, Инҗил», 2015 ел, Изге Китапны тәрҗемә итү институты). КТ хәрефләре белән билгеләнгән өзекләр Изге Язманың инглиз теленә Киңәйтелгән тәрҗемәсеннән (КТ) алынган. (The Amplified Bible).

Әйт аларга: *Мин аларны яратам*
*Аллаһы Тәгалә сезне ярата — бу гади хакыйкать*

© 2021, Джойс Майер
© УК «МЕДИА-МИР», Мәскәү
Russian

Тәрҗемә: Фазлиәхмәтова Рузилә
Мөхәррире: Фазлиәхмәтова Рузилә
Верстка: Афанасьева Алинә

TELL THEM I LOVE THEM
The Simple Truth About God’s Love for You

ISBN 978-0-446-69205-2
© 2003, 2007 Joyce Meyer
Life In The Word, Inc.
P.O. Box 655
Fenton, Missouri 63026

Бөтен хокуклар авторлык хокукы турындагы халыкара канун белән якланган. Китапның эчтәлеге һәм тышлыгы бөтен килеш яки өлешләп, теләсә нинди торышта, формада авторның язма рөхсәтеннән башка кабатлана яки кулланыла алмый.

# Эчтәлек


| | |
|---|---|
| Кереш сүз | 6 |
| Аллаһы сезне ярата! | 10 |
| Мин җитәрлек дәрәҗәдә яхшымы? | 19 |
| Мәхәббәт — ул мөнәсәбәтләр | 31 |
| Мәхәббәт, ышанып тапшыру һәм иман | 41 |
| Куркудан ирекле булу | 50 |
| Мәхәббәт бирә | 58 |
| Ходайның мәхәббәте сине үзгәртер | 65 |
| Тәүбәгә килү догасы | 70 |

# Кереш сүз

Һәр кешегә Ходай Тәгаләнең нәкъ аны, шәхесне яратуы турындагы шәхси ачылыш алу барыннан да ныграк кирәк — мин моның шулай икәненә ышанам. Ходай белән ныклы һәм якын мөнәсәбәтләр төзүдә һәм, мәсихче буларак, кешенең тормышы уңышлы булуда нәкь шушы белем нигез булып тора. Ходай Тәгаләнең безне яратуы турында баш белән генә белү безгә кирәк түгел, безгә йөрәгебез белән ачылыш алырга кирәк. Андый ачылышны Изге Рух кына бирә ала. Әгәр дә Ходайның безне яратуы турында фикер йөртсәк, безнең тормышыбыздагы Ходайның яратуы күренгән очракларны

күрә белсәк, бу ачылышны, дога кылып, Ходай Тәгаләнең Сүзеннән эзләсәк — Изге Рух безгә бу ачылышны бирер.

Ходай Тәгалә бөтен дөньяны шулкадәр ярата, Ул Үзенең Углын бөтен кешелекнең гөнаһлары өчен корбан булып үлү өчен җиргә җибәргән — бу фактларны кабул итеп алу кешегә бер дә кыен түгел. Ә менә икенче бер фактны кабул итеп алу күп тапкырга кыенрак: Ходай Тәгалә нәкъ менә сине шулкадәр нык ярата, әгәр дә җир йөзендә син бер үзең генә яшәгән булсаң да, Ул Гайсәне бердәнбер кеше өчен — синең өчен корбан булып үлергә җибәргән булыр иде.

Күп еллар мин үземнең мәсихче тормышымнан канәгатьсезлек кичердем һәм, ниһаять, Ходай Тәгаләнең мине яратуы турында ачылыш алдым. Үзенең мәрхәмәте аркылы бөтен кешелекне генә түгел, ә мине шәхсән яратуы турында Ул миңа Үзенең Изге Рухы аркылы ачылыш бирде. Нәкъ менә шушы ачылыш минем бөтен тормышымны, минем Ходай Тәгалә белән булган мөнәсәбәтләрне үзгәртте. Минем догам: бу китапны укыган вакытта, Ходай Тәгаләнең

сезне шәхсән яратуы турындагы ачылышны кабул итеп алсагыз иде. Китапны ашыкмыйча, фикер йөртеп укыгыз, бу китапны Ходайның мәхәббәте турында өйрәнү өчен әсбап итеп кулланыгыз. Изге Язмадан алынган өзекләр турында, мин сезнең белән уртаклашкан фикерләр турында уйланыгыз.

Ходай сезне бик нык ярата. Ул Үзенең мәхәббәте турында сезнең белүегезне тели, мин һәр көн аның мәхәббәтен тойган кебек, сезнең дә һәр көн тормышыгызның һәр өлкәсендә Аның мәхәббәтен тоюыгызны тели. Хәзер мин басынкылык белән, башымны иеп, бу китапны сезнең кулларыгызга тапшырам, чөнки мин беләм: Ходайдан башка мин буш урын, чөнки Ходайның сүзен аңлау һәм Ходайның мәхәббәте турындагы ачылышлар миңа бары тик Ходайның мәрхәмәте белән бирелгән.

ӘЙТ АЛАРГА:

# *Мин аларны яратам*

# Аллаһы сезне ярата!

*«Аллаһы дөньяны шулкадәр яратты ки, Углына иман итүчеләрнең берсе дә һәлак булмасын, ә мәңгелек тормыш алсын өчен, Үзенең бердәнбер Углын бирде».*

Яхъя 3:16

Ходай Тәгалә безне Үзенең гайләсе итеп күрергә тели, безнең Әтиебез булырга тели. Без Ходай белән якын мөнәсәбәтләрдә булу өчен яратылганбыз. Мәсих, безнең өчен үлеп, безгә искиткеч тормыш бүләк иткән. Без, Аның уллары һәм кызлары буларак, шул искиткеч тормышта яшәү өчен яратылганбыз. Ходай Үзенең

ышанычлы икәнен белүебезне, Аңа таянуыбызны, Аны яратуыбызны һәм Аңа безне яратырга мөмкинлек бирүебезне тели. Аңа тормышыбызны ышанып тапшыруыбызны, мохтаҗлык вакытында Ходайга мөрәҗәгать итуебезне тели. Аның теләге — һәрберебез белән шәхсән мөнәсәбәттә булу.

Яхъя бәян иткән Яхшы хәбәрнең 3-нче бүлегеннән 16-нчы аятьне күпчелек кеше гомумән анлый. «Әйе, Гайсә Мәсих бөтен дөнья өчен үлгән», — дип әйтәбез без. Ләкин «бөтен дөнья» ниндидер билгеле булмаган шәхесләр турында түгел. Мәсих безнең һәрберебез өчен үлгән. Ул синең өчен үлгән!

Әгәр дә җир йөзендә бердәнбер кеше син булсаң, Гайсә бары тик синең өчен үлгән булыр иде — моның шулай икәненә ышан. Ул бөтен газапны синең өчен генә кичергән булыр иде. Ходай Тәгалә сине шулхәтле нык ярата, Аның яратуы мәңгегә! (Иремия 31:3-не карагыз)

Шулай бер көнне, машинада барганда, Ходай минем йөрәгемә мөрәҗәгать итеп әйтте: «Джойс, син Минем күз карасы!» Шунда ук

дошман җавап бирде: «Бу горурлык түгелме соң? Син үзеңне кем дип уйлыйсың?» «Әйе шул, миңа шундый уйларны башыма кертергә ярамый», — дип килештем мин. Безнең һәрберебез үзенчәлекле, һәрберебез бик булдыклы һәм искиткеч сәләтле — бу чыннан да шулай, ләкин без үзебез турында башкача уйлыйбыз. Безнең һәрберебезне Әтиебез уникаль һәм үзенчәлекле итеп яраткан. Ходай Тәгалә күптөрлелекне ошата. Ул сезне үзегезгә бер төрле, берәүгә дә охшатмыйча, бердәнбер итеп барлыкка китергән. Шуңа күрә үзегезне бүтән кешеләр белән чагыштыруыгызны һәм сезнең бүтәннәр кебек булырга тырышуыгызны теләми. Ул сезне нинди итеп барлыкка китергән, сез Аның өчен нәкъ шундый: сез Аның өчен бердәнбер, үзегезгә бер төрле, үзенчәлекле.

Ходай әйткән сүзләр турында уйланып калдым. Шул турыда фикер йөрткәндә, күз алдыма сурәт килде: кибеттә, бик зур алма киштәсе каршында, бер хатын-кыз басып тора. Ул игътибар белән бөтен алмаларны карап чыкты да, кулын сузып, үзенә иң ошаганын, иң яхшы алманы

сайлап алды. Шул вакытта Ходай миңа әйткән сүзнең мәгънәсенә төшендем: Ходай өчен «иң яхшы алма» — мин! Мин үземә бер төрле. Бу сүзләр бәлки бик горур булып ишетелә торгандыр. Ходай һәрберебезгә шулай итеп карый, бу сүзләрне һәр кешегә әйтә. «Син башка кешеләргә караганда яхшырак», — дип әйтә икән Ходай дип уйлый күрмәгез. Юк, Ул алай дип әйтми. Ходай өчен безнең һәрберебез үзенә бер төрле. Бу турыда Ул Үзенең сүзендә әйтә, ә Аның сүзе безнең һәрберебез өчен. Син Ходайның «күз карасы»!

Ул вакытта мин Ходайның бу сүзен кабул итмәдем, чөнки үз-үзең турында шундый фикер бик дөрес булмас дип уйладым. Ә менә бер-ике көн үткәннән соң, Зәбур китабының 16-нчы бүлеген ачсам, 8-нче аятькә күзем төште. Анда: «Күз карасын саклаган күк сакла мине, канатларың астына алып сакла», — дип язылган (Патша тәрҗемәсе). «Кара әле син аны», — дип кычкырып җибәрдем мин. «Димәк, теге сүзләрне миңа чыннан да Ходай әйткән. Мин Ходайның күз карасы!» Шул көннән башлап, шушы сүзләрне

исемә төшергән саен, мин үземне бик үзенчәлекле итеп хис итә башладым. Ә син беләсеңме соң, син Ходай өчен бик нык кадерле?! Ул синең үзеңне бик үзенчәлекле, әһәмиятле, кыйммәтле һәм сөекле итеп хис итүеңне тели.

Һәр кеше сөекле булырга тели — бу теләкне һәр кешенең күңеленә Ходай Тәгалә салган. Күп кеше Ходай Тәгаләнең бөтен дөньяны сөюенә ышана, Гайсәне яратуына ышана, ләкин безнең һәрберебезне шәхсән яратып сөюенә ышанырга бик авыр. Ходайның сүзендә язылган: Ул безне Гайсәне яраткан кебек үк нык ярата. Без бу турыда Яхъя 3:16-да укый алабыз. Ул, Гайсәне яратып сөйгән һәм фатихалаган кебек, безгә Үзенең мәхәббәтен бүләк итәргә, безнең тормышыбызны фатихаларга тели.

Яхъя бәян иткән яхшы хәбәрдә, 5-нче булек, 20-нче аятьтә язылган: «Ата Үзенең Углын ярата һәм барлыкка китерә торган һәр нәрсәне Аңа ача (ачып күрсәтә). Сезнең исегез китәрлек тагын да зуррак эшләрне ачып күрсәтер әле ул Аңа» (КТ). Ходайның бу сүзләрен мин үз сүзләрем белән болай дип әйтәм: «Мин бөтен бөек эшләрне

Гайсә аша булдырам, Гайсә аша тагын да бөегрәк эшләр булдырырмын — сезнең исегез китәр, шаккатырсыз». Безнең рәхәтлек өчен һәм без ләззәт алсын өчен бөек эшләр булдырып, Ходай безне шаккатырырга тели. Без бу китап юлларын укыйбыз, ләкин бик еш Ходайның бу эшләрне безнең өчен генә түгел, ә безнең аша башкарырга теләгәненә игътибар итмибез. Гайсә аркылы Үзе бар иткән бөтен могҗизаларын без күреп, Аның безнең аркылы да шундый бөек эшләр кылырга теләгәненә безнең ышануыбызны тели Ходай. Гайсә әйткән: «Сезгә хак сүз әйтәм: Миңа иман итүче (Мин) башкарган эшләрне (башкарыр) һәм алардан да бөегрәк эшләр башкарыр; чөнки мин Атам янына барам» (Яхъя 14:12).

Ходай кешеләрне ярата, шуңа күрә көн саен шундый күп искитәрлек эшләр кыла, ә кешеләр ул эшләрне күрмиләр дә. Мисал өчен: һәр иртә белән кояш чыкканда — синең өчен чыга; бихисап күп төрле чәчәкләр синең хозурлыгың өчен ата. Безнең өчен барлыкка китерелгән җир йөзе искитәрлек итеп яратылган — Ходай безне шулай итеп сөендерергә тели. Башлангыч кита-

бының 1-нче бүлегендә язылган: Ходай кешегә җир йөзендә өстенлек итәргә биргән һәм бөтен булган нәрсәне Ходайга һәм кешегә хезмәт итүдә файдага кулланырга кушкан. Үз вакыты белән яңгыр яуганда, яңгыр синең өчен ява. Кар яуса, кар да синең өчен ява. Ходай Тәгалә синең һәр адымыңны юнәлтә, һәр минут синең турында кайгыртып тора.

Канун 7:9-да язылган: «Шуңа күрә онытмагыз: Раббы Аллаһыгыз — бердәнбер Аллаһы, Ул тугрылыклы Аллаһы. Аны яратканнарга, Аның әмерләрен үтәүчеләргә, Үзенең килешүенә тугры кала Ул, мәрхәмәтен меңенче буынга кадәр саклый». Ходайның безгә карата булган мәхәббәте чиксез һәм шартсыз. Без үзебезнең булдыксызлыгыбыз, хаталарыбыз белән Ходайны ялкытып бетердек дип уйлыйбыз. Әлбәттә, бу алай түгел, Ходай беркайчан да бездән ялыкмаячак. Нәрсә генә эшләсәгез дә, Ходайның сезгә карата булган мәхәббәте кимемәячәк. Мәхәббәт ул Ходайның безгә карата булган хис-тойгысы гына түгел, мәхәббәт ул Ходайның табигате. «Мине Ходай ничек ярата алсын, мин бит бик

начар кеше», — дип уйласаң, ялгышасың. Синең чокыр никадәр тирән булуга карамастан, Ходай сине ул чокырдан тартып чыгара ала. Әгәр дә син чын күңелеңнән гафу үтенсәң, Ходай синең гөнаһларыңны кичерә: кичерә генә түгел, Ул аларны оныта, көн чыгышы көн батышыннан никадәр ерак булса, безнең гөнаһларыбызны да шулкадәр еракка этәрә (Зәбур 102:12-не карагыз).

«Мин Гайсәне йөрәгемә кабул иттем, Мин Гайсәне яратам», — дип әйтерсең син бәлки. Мин сиңа шундый сорау бирим: «Ходай сине ярата! Син моңа ышанасыңмы?»

Ходайның мәңгелек, бер нинди шартсыз булган мәхәббәте бик гади, ләкин шул ук вакытта нигез булып тора торган фундаменталь хәбәр: аннан башка без калган нәрсәләрне аңлый алмыйбыз, сәламәтләнә алмыйбыз. Сез, әлбәттә, Ходай турында тагын күп нәрсәләр белерсез; бик тырышып Ходайның Сүзен өйрәнерсез; күп нәрсәләргә төшенерсез. Ләкин Аның нәкъ менә сезне бик нык яратуын һәм бер шартсыз яратуын чын хакыйкать итеп кабул итмәсәгез,

Ходай белән мөнәсәбәтләрегез тирән була алмас. Моның шулай икәненә ышаныгыз.

Без Ходайдадан кабул итеп алган һәр нәрсәне ышану аркылы кабул итеп алабыз. Ә иман мәхәббәт белән хәрәкәт итә (Гәләтиялеләргә 5:6-ны карагыз). Ходайның безне яратуын кабул итмичә торып, без Ходайдан башка бер нәрсә дә кабул итә алмаячакбыз.

Ходайның мәхәббәте безгә курыкмыйча яшәргә ярдәм итә (1-нче Яхъя 4:18-не карагыз). Курку булмаганда гына без тормыш белән хозурлана алабыз, шул вакытта гына тормыш безгә нинди эшне башкару өчен бирелгән, шул эшне башкара алабыз. Ходай сезне бернәрсәгә карамыйча ярата. Ә син моңа ышанасыңмы?

Яхшы гамәлләр кылып, Ходайның мәхәббәтенә лаек булу мөмкин түгел. Сиңа бары тик Ходайның мәхәббәтенә ышанырга һәм аны кабул итеп алырга гына кирәк.

# Мин җитәрлек дәрәҗәдә яхшымы?

*«Мондый өмет беркайчан да алдамый, ялгыш юлга кертеп җибәрми, беркайчан да безне оятта калдырмый, чөнки безгә бирелгән Изге Рух белән Ходайның мәхәббәте йөрәкләребезгә яудырылган.*

*Үзебезгә ярдәм итә алырлык көчебез булмаганда, без әле ярдәмгә мохтаҗ булганда, Мәсих, билгеләнгән бер вакытта, имансызлар өчен үлгән.*

*Әгәр берәрсе гадел кеше өчен үлсә, бу искиткеч хәл булыр иде. Бәлки берәрсе мәрхәмәткә лаек, юмарт, яхшы кеше өчен үлгән дә булыр иде.*

*Ләкин Мәсих (Мәсих, Ходай майлаган Зат), без гөнаһлы вакытта безнең өчен үлүе белән Үзенең мәхәббәтен исбат итте.*

*Без Гайсәнең каны түгелүе аркылы акландык (тәкъва булдык, Ходай каршында дөрес хәлгә килдек). Әлбәттә (һичшиксез) Ул безне Ходайның ачуыннан һәм канәгатьсезлегеннән коткарыр.*

*Без Ходай белән дошман булганда Углының үлеме аркылы Ходай белән татулашканбыз икән, инде хәзер, татулашкач, Аның (үледән терелтә торган) тормышы аркылы котылырбыз (һәр көн саен гөнаһның көченнән, хакимлегеннән котылырбыз)».*

Римлыларга 5:5 – 10, КТ

Безнең эш-гамәлләребез дөрес булганда, Ходайның безне яратуына ышанырга безгә җиңелрәк. Кыенлык менә нәрсәдә: күпчелек кеше үз-үзен яратмый, шуңа күрә: «Ходай Тәгалә мине нәрсә өчен яратсын?» — дип уйлый. Изге Язмада язылган: «Син шулай игътибар күрсәт-

кән инсан кем ул? Син шулай кайгырткан адәм баласы кем?» (Зәбур 8:5). Безне Ходай бар иткән. Ходай безне ярата, чөнки Ул безне ярата — Ул Мәхәббәт (1 Яхъя 4:16 ны карагыз). Ходай безне ярата, чөнки Ул шулай тели.

Ходай сине ярата, чөнки син бердәнбер, үзенчәлекле, үзеңә бер төрле, сине беркем дә кабатлый алмаячак. Син минем кебек булырга тырышырга тиеш түгелсең, ә мин синең кебек булырга тиеш түгел. Әгәр дә син үзеңне башка кешеләр белән чагыштыра башласаң, аларны кабатларга һәм алар белән ярышырга тырышсаң — син иң бәхетсез кеше. Әгәр шулай эшләсәң, син шайтанга мөмкинлек бирәсең, ул: «Син җитәрлек дәрәҗәдә яхшы түгел», — дигән сүзләргә сине ышандырырга тырыша. Ләкин сиңа җитәрлек дәрәҗәдә яхшы булырга тырышырга кирәк түгел. Гайсә Ходай алдында җитәрлек яхшы булган. Гайсә синең гөнаһларың өчен түләгән һәм син лаек булган җәзаны Үз өстенә алган.

Изге Язмада язылган: «Әгәр Ул син гөнаһлы вакытта ук синең өчен үлгән икән, сине Үзе-

нең каны белән аклаганнан соң, әлбәттә, хәзер Ходай сине бик нык ярата» (Римлыларга 5:8-9). Ходай сине шулкадәр ярата: һәр көн саен синең хаталарыңны һәм кимчелекләреңне кичерә, көн саен сине шакшының һәр төреннән арындыра.

Минемчә, Ходай безнең кимчелекләргә һәм безнең төгәл эшли алмавыбызга менә ничек карый. Бу бер мисал: 3 – 4 яшьлек кызны күз алдыгызга китерегез. Ул һәрвакыт әнисенең өй эшләрен ничек итеп башкарганын күреп тора. Ул әнисен шул хәтле нык ярата, аңа ярдәм итәргә теләп, чиләккә су сала, чүпрәк ала һәм, бик тырышып, тәрәзә юа башлый. Аннары, берничә кәгазь тастымал белән, тәрәзә пыяласын сөртә. Бөтен тәрәзә буенча, буй-буй булып, сабын эзләре кала, ә әнисенең иң яхшы чүпрәге эштән чыга. Кыз әнисенә, шундый татлы тавыш белән: «Әнием, әнием, мин тәрәзәне юдым. Мин сиңа ярдәм иттем, чөнки мин сине бик яратам», — дип дәшә. Кызын ярата торган әни кеше: «О, кызым, бик яхшы итеп югансың. Ярдәмең өчен рәхмәт сиңа», — дип әйтәчәк. Ә соңыннан, кызы башка бер эшкә игътибарын юнәлткәч,

тәрәзәне үзе тәртипкә китерәчәк. Ә соңрак: «Бу яки икенче эшне ничек яхшырак итеп башкару турында син һәрвакыт миннән сорый аласың, кызым», — дип, кызын өйрәтәчәк.

Ходай да безнең белән нәкъ шулай эшли. Ул һәммә нәрсәне яхшы якка борып җибәрә ала, чөнки без Аны яратабыз һәм без Аның нияте буенча чакырылган кешеләр (Римлыларга 8:28-не карагыз). Әгәр без, бөтен көчебезне куеп, Ходайга ярарга тырышабыз икән — Ходай бездән моннан да артыгракны көтми. Әгәр дә син, ярдәм сорап, Аңа мөрәҗәгать итәсең икән, Ул сиңа һәр эштә ярдәм итәчәк. Син тагын да ныграк Аңа охшасын өчен һәм Аның шөхрәте синдә тагын да ныграк үссен өчен, Ул сине үзгәртәчәк (2-нче Көринтлеләргә 3:18-не карагыз).

«Ходай җибәргән Зат Ходай сүзләрен сөйли (Ходайдан хәбәр җиткерә); чөнки Ходай Аңа Изге Рухны аз гына итеп яки күпмедер күләмдә итеп кенә бирми. Изге Рух буләге чиксез итеп бирелә. Ата Углын ярата һәм бөтен нәрсәне Аның кулларына тапшырган (ышанып тапшыр-

ган, биргән)» (Яхъя 3:34 – 35, КТ). Бервакыт, шушы аятьне укыганда, шатлыгымнан еладым, чөнки мин бер әйберне анладым: Ходай безгә Изге Рухны чикләп бирми. Ул безгә аз-аз гына итеп моны, яки аз-аз гына итеп тегене бирми. Ходай бик юмарт, син Аннан сораган әйберне яки син уйлаган әйберне Ул сиңа артыгы белән, һәр үлчәмнән арттырып бирә ала (Эфеслеләргә 3:20-не карагыз).

«Чөнки син изге халык, синең Раббың, Аллаһың өчен аерып алынган халык. Раббы Ходай бөтен халыклар арасыннан сине Үз халкы итәр өчен, син Аның Үз халкы булсын өчен сайлап алган. Раббы сине күпсанлы булганың өчен яратып, сайлап алмаган, син башка халыкларга караганда азсанлы» (Канун 7:6 – 7, КТ). Бу аятьләрдә язылган сүзләр — куаныч өчен бик яхшы сәбәп. Ходайның сүзләрен үз сүзләрем белән әйтәм: «Мин сине яраттым. Мин сине изге дип атадым. Мин сине син яхшы булган өчен сайлап алмадым. Мин сине яратам — шуның өчен мин сине сайлап алдым, ә син яхшы булган өчен түгел».

Ә бүген Ходай синнән нинди гамәлләр көтә? Аның мәхәббәтенә ышанып, шул мәххәббәтне кабул итеп алуыңны көтә. Ходайга үзеңнең хаталарың һәм кимчелекләрең турында сөйләвеңне туктат. Ничек кенә булмасын, Син анын өчен сюрприз түгел. Син Аның янына килгәндә, Ул синең турында инде бөтен нәрсәне белә, шул исәптән, син әле ясамаган хаталарыңа тикле белә.

Безнең күпчелегебезнең зур кыенлыгы, проблемасы булып менә нәрсә тора: без үзебезгә үзебез ошамыйбыз. Шул сәбәпле, үзебезнең Ходайга ошавыбызны күз алдына да китерә алмыйбыз. Кемнең дә булса берәүнең безне яратуына ышана алмыйбыз, шуңа күрә Ходайның безне яратуына да ышанмыйбыз. «Мине ничек яратырга була? Минем кимчелекләрем шулкадәр күп», — дип уйлыйбыз без. Әгәр дә син үзең турында: «Мин чиркандыргыч кеше», — дип уйлыйсың икән, синең эш-гамәлләрең дә шулай ук чиркандыргычтыр, чөнки син үзең турындагы уйларыңнан яхшырак була алмыйсың. Кеше үзенең башындагы уйлардан, үзе

турында үзе уйлап чыгарган сурәттән дә яхшырак була алмый.

Кайчандыр минем дә шундый кыенлыгым бар иде: мин үземә үзем ошамый идем, үземне яратмый идем. Күп тапкырлар, үземнең уйлавымча мин нинди булырга тиеш, үземне шулай итеп үзгәртергә тырыштым. Мисал өчен, мин үземне бик күп сөйләшә торган кеше дип уйлый идем, шуңа күрә бер сүз дә сөйләшмәскә, тын гына торырга тырыша идем. Ләкин, сөйләшмичә генә, тын гына утырганда, минем кәефем начарлана, депрессия башлана, миңа бик күңелсез була һәм мин күңел төшенкелегенә чума идем. Кешеләр миннән: «Нигә бер сүз дә сөйләшмисең?» — дип сорыйлар иде. Ә мин, эчемнән генә аларга җавап итеп: «Сез бит үзегез миңа: «Бик күп сөйләшәсең», — дип әйтәсез. Шуңа күрә сөйләшмим. Шуңа күрә миңа бәйләнмәгез», — дип уйлый идем. Күп еллар буе мин үземне үзгәртергә тырыштым, шул сәбәпле үземә күп кенә борчулар китердем. Минем белән һәр күңелсез очрак килеп чыккан саен, шайтан миңа: «Менә син нинди начар», — дип

әйтү очрагыннан кулланмыйча калмый иде. Без үз-үзебезне гаепләсен өчен, үзебезне гаепле итеп хис итсен өчен, ул һәр шундый очракны кулланырга тырыша. Шуңа күрә мин сезне бик яхшы аңлыйм, бер-бер нәрсә кылган очракта, Ходайның сезне яратуына ышану бик кыен.

Гаептән һәм үз-үзеңне гаепләүдән Ходай Тәгалә синең ирекле булуыңны тели. Ләкин, гаептән котылу өчен, сиңа иман һәм кыюлык кирәк. Ә син шуны беләсеңме: үз-үзеңне гаепләү хисе ничек кенә тирән булмасын, син кылган начар гамәлне ул хис аклый алмый? Ә бит, әйткәнемчә, начар гамәл кылганнан соң, Ходайның сине яратуына ышану бик авыр. Җитмәсә, синең нинди начар кеше икәнең турындагы уйлар белән шайтан сине җафалаячак: «Ничек шулай эшли алдың? Хәзер үзең турында нәрсә уйлыйсың инде? Ходай сине бүтән беркайчан да фатихаламаячак. Үзеңне яхшырак тотырга идең. Хәзер син Гайсә турында сөйли алмыйсың инде. Ходай сиңа бүтән эш кушамаячак. Синең догаларыңа бүтән җавап бирмәячәк. Син дөрес итеп яшәргә сәләтле түгел, ахры».

Ходайга: «Атам, мин хата җибәрдем. Зинхар өчен, кичер мине. Мин чын күңелемнән үкенәм. Син мине кичерәсең, мин моңа ышанам. Рәхмәт Сиңа», — дип әйтү өчен, нәкъ менә шундый минутларда сиңа иман һәм кыюлык кирәк тә инде. Гайсә синең бөтен гөнаһларың өчен түләде, син тулысынча кичерелдең, гаепләү хисеннән һәм гаептән син бөтен килеш азат ителдең — менә хәзер инде бу турыда шайтанның исенә төшерсәң була. Ходай Сүзенең кодрәте синең иманыңны һәм Ходайга таянуыңны ныгытыр. Шул вакытта гына син тормышка куанып, ләззәтләнеп һәм башка кешеләрне шатландырып яши алырсың.

«Ни өчен мин бер үк хатаны һаман саен кабатлыйм», — дип сорарсың син. Элек мин дә үземә шул сорауны гел бирә идем. Аннары үземне гаепләмәскә карар кылдым. Син дә кылган начар гамәл өчен үз-үзеңне гаепләүдән тукта, шуннан соң гына син ул хатаны кабатламый башлаячаксың.

Гаеп, үз-үзеңне гаепләү безне төшенкелеккә бирелдерә, җәфалый, эчке азатлыктан мәхрүм

итә, көчсезләндерә, шуңа күрә гөнаһка каршы торырга көчебез калмый. Ходайның кичерү бүләген кабул итеп алу өчен һәм гөнаһка каршы тору өчен сиңа кыюлык кирәк. Ходай Сүзенә ышанып һәм үзегезне гаепләмичә яшәргә карар кылыгыз. Сезнең шундый карарыгызны күреп, шайтан сезгә болай диячәк: «Син нәрсә, син әллә шушы начар эшең була торып, борчылмаска җыенасыңмы? Һич югында, берничә сәгать булса да газапланырга тиешсең, чөнки син шулкадәр начар эш эшләдең». Ә сез: «Юк, мин борчылырга җыенмыйм. Җәфаланырга да уйламыйм», — дип әйтегез. Шуннан соң Ходайдан гаеп хисен үз өстегездән алып ташларга һәм тормышны дәвам итәргә ярдәм сорагыз. Бәлки башта, берничә тапкыр сезгә шулай эшләргә авыр булыр, ләкин, тора-бара, һәр тапкыр җиңелрәк булачак.

Ишагыйя китабының 53-нче бүлегендә язылган, Гайсә безнең гөнаһларны Үзенә алганда, Ул шулай ук Үзенә безнең гаепне һәм үз-үзебезне гаепләүне дә алган. Шайтан сезнең һәрвакыт үз-үзегезне гаепләвегезне тели. Ни өчен? Чөнки,

үзегезне гаепләгән вакытта, Ходайның сезне яратуына ышанырга сез сәләтле түгел. Гаепләү сине Ходайдан аера, һәм син Ходайның хозуры белән ләззәтләнә алмыйсың. Гаепләү синең карашыңны Ходайдан үзегезгә һәм кылган эшегезгә күчерә.

Үзегезне бүтән гаепләмәгез. Ышаныгыз: әгәр Ходай, синең бөтен гөнаһларыңны һәм начар гамәлләреңне каплау өчен Аның мәрхәмәте җитәрлек дип әйткән икән, димәк бу шулай. Ул сине ярата һәм сиңа мәрхәмәт һәм ярлыкау бүләк итә — сиңа аларны кабул итеп алырга кирәк.

# Мәхәббәт — ул мөнәсәбәтләр

*«Ходайның безне назлы итеп яратуы турында без беләбез (күзәтү һәм тәҗрибә нигезендә аңлыйбыз, төшенәбез, моның шулай икәнен кабул итәбез) һәм моңа ышанабыз (ныгытып тотып торабыз, бөтен килеш ышанып тапшырабыз һәм таянабыз). Ходай ул мәхәббәт. Ярата торган кеше Ходайда, Ходай анда».*

1-нче Яхъя 4:16, КТ

Бу аятьтә әйтелгәнчә, Ходай ул — мәхәббәт, ул мәхәббәтне безнең тоюыбызны һәм моның

шулай икәненә акылыбыз белән төшенүебезне тели. Ни өчен Ходайның мәхәббәтен аңлау бик мөһим? Чөнки, Ходай сине ничек кенә нык яратмасын, әгәр син ул мәхәббәт турында белмисең икән, Аның мәхәббәтен аңламыйсың икән, ул мәхәббәт сиңа ярдәм итми. Әгәр сине берәрсе бик нык ярата икән һәм яратуын синнән яшерми икән, сиңа бит шундый рәхәт. Әгәр син, берәүнең сине яратуы турында беләсең икән, син бит үзеңне бик яхшы хис итәсең. Ходай сине ярата һәм Сиңа Үзенең мәхәббәтен күрсәтергә тели. Һәрберебезне Ул Үзе белән бик тирән, якын, шәхсән мөнәсәбәтләргә чакыра. Безнең һәр эшебездә катнашырга тели. Безнең Үзе белән, яхшы иптәш белән аралашкан кебек, аралашуыбызны тели.

Ходай белән син үзеңне бик якын һәм тугрылыклы, ышанычлы мөнәсәбәттә дип әйтә аласыңмы? Югарыдан тууыбыз белән без үзеннән-үзе Ходай белән тулы мөнәсәбәтләргә кермибез. Без кешеләр белән мөнәсәбәтне ничек төзибез, Ходай белән дә мөнәсәбәтне шулай итеп тырышып төзергә тиешбез. Мин Ходай белән чын, җитди мөнәсәбәтләр төзи башлаган

вакытта, инде күп еллар мәсихче идем. Һәр якшәмбе бердәмлеккә бара идем, хәтта нәрсә беләндер ярдәм дә итә идем. Ләкин Ходай минем тормышымда үзәк урынны алып тормый иде. Мин тормышымда бушлык тойдым һәм бу хәл белән бер дә канәгать түгел идем. Ә хәзер, иртән уяну белән, иң башта Ходай турында уйлыйм. Йоклар алдыннан да мин Ходай турында уйлыйм. Көн буе мин Аның белән сөйләшеп йөрим һәм, барыннан да ныграк, Ходаема хезмәт итәргә һәм Аңа ярарга тырышам.

Һәр кешенең эчендә Ходай буш урын, бушлык калдырган. Ул бушлыкны Ходай Үзе генә тутыра ала. Сез хыялланган яки сез омтылган бер генә нәрсә дә ул бушлыкны тутыра алмый. Ул бушлыкны бүтән бер әйбер белән дә тутырып булмый. Үзегезгә шундый сорау бирегез: Ходай белән булган мөнәсәбәтегез ни дәрәҗәдә җитди? Ходайны һәм Аның ихтыярын тормышыгызда беренче урынга куярга сез әзерме? «Без Аңарда яшибез, хәрәкәт итәбез һәм көн күрәбез» (Рәсүлләр 17:28). Паул әйткән бу сүзләрне үзегезгә әйтергә сез әзерме?

Ходай сине ярата, син Аның өчен бердәнбер. Ул сине үзе белән мөнәсәбәтләрдә булу өчен барлыкка китергән — бу Аның сиңа карата иң камил ихтыяры һәм иң зур теләге. Һәр иртә белән Ул сиңа шундый сүзләр әйтә: «Хәерле иртә. Мин сине яратам». Әгәр дә синең беркайчан да Аның сиңа шундый сүзләр әйткәнен ишеткәнең булмаса, тыңлап кара! Һәм син ул сүзләрне ишетерсең.

Минем дустыма бервакыт шундый күренеш күренгән: иртә белән, кешеләр йокыларыннан уянгач, кешеләр белән сөйләшү өчен, Ата аларның өйләренә керә, урындык алып, утыра. Кешеләр Аның янына киләләр дә шунда ук кире борылып китеп баралар: «Ходай, соңрак сөйләшербез, ярыймы», — диләр алар. — «Монда утырып тор, хәзер бераз эшлисе эшләремне эшлим дә, соңрак Синең яныңа килермен, сөйләшербез», — диләр. Көн ахырына якынлаша. Ходай, борчылып, ул өйдән чыгып китә, чөнки берәү дә Аның белән сөйләшергә вакыт тапмый. Кешеләр үзләренең мөһим эшләре белән мәшгуль, аларның Ходай өчен вакытлары юк.

Сезнең дә эшегез шулай ук күпме? Әгәр дә сезнең дога кылырга һәм Ходай белән сөйләшергә вакытыгыз юк икән, димәк, сез дә бик мәшгуль. Ходайны яратуыгыз турында Аңа әйтергә вакыт табарга кирәк. Тормыш ахырына җиткәч, сезнең Ходайдан башка бер генә эшегез дә, бер генә нәрсәгез дә калмаячак. Бу чыннан да шулай. Әгәр дә сез хәзер Ходай белән мөнәсәбәт төземисез икән, соңыннан, Ходай каршына килеп баскач, соң була.

Минем әтием күптән түгел вафат булды. Үләргә өч ел кала, ул Гайсәне үзенең Коткаручысы итеп кабул итте, мин бу турыда бик зур куаныч белән әйтәм. Минем әтием күкләргә китте, ләкин ул монда, жирдә Ходай белән шатлыклы гомер итү мөмкинлегеннән куллана алмады. Минем әти һәрвакыт үзе өчен яшәде.

Гомерең ахырында, вакытыңны мөһим булмаган әйберләргә әрәм иткәнең өчен, кызганыч булырлык булмасын. Вакыт — Ходай биргән бик кыйммәтле бүләк һәм без ул бүләкне акыллы итеп кулланырга тиешбез. Вакытны кире кайтарып булмый. Ходай белән уздырган вакыт сезгә

искиткеч бүләк алып килер, ә сез бик кыйбат итеп түләгән күп нәрсәләрнең бәясе арзан булып чыгар.

Мин сезгә менә нәрсә тәкъдим итәм: үзегезгә Ходайның мәхәббәтенә ышанырга һәм Аның мәхәббәтен кабул итәргә ярдәм итү өчен, бүгеннән башлап, унике ай буе, бөтен фикерегезне Ходайның мәхәббәте турында туплагыз һәм Аның мәхәббәте хакында язылган Ходай сүзен укыгыз, өйрәнегез. Ходайның мәхәббәте сезнең тормышыгызны тулы итәр, шатлык һәм тынычлык белән тутырыр, сезнең тормышыгыз кызыграк, эчтәлеклерәк булыр. Аның балалары буларак, Ул безнең тынычлануыбызны, тормыш белән, Ходай белән мөнәсәбәтләрдән ләззәтләнеп яшәвебезне тели. Ходайны яхшырак белү өчен, Изге Язмада Аның турында язылган урыннарны өйрәнегез.

1-нче Яхъя 4:16-да болай дип язылган: «Ходайның безне назлы итеп яратуы турында без беләбез (күзәтү һәм тәҗрибә нигезендә аңлыйбыз, төшенәбез, моның шулай икәнен кабул итәбез), моңа ышанабыз (таныйбыз,

ныгытып тотып торабыз, бөтен килеш ышанып тапшырабыз һәм таянабыз). Ходай ул мәхәббәт. Ярата торган кеше Ходайда, Ходай анда» (КТ). Иртә белән уянганда, син бәлки узеңне сөекле итеп хис итмисеңдер. Бәлки синең кәефең начардыр, бәлки син көне буе зарланасыңдыр. Тизрәк сиңа яхшы хәбәрне җиткерәсем килә: үз-үзеңә рухландыра торган иман сүзләрен әйтеп, кәефеңне һәм мөнәсәбәтеңне үзгәртә аласың. «Ходай мине бик нык ярата! Мин Аның күз карасы, күз нуры! Ходайның минем тормышыма карата бик яхшы уйлары бар», — дип үзегезгә кычкырып әйтегез. Әгәр дә сез, кыен хәлләрегез турында сөйләүгә караганда, Ходай турында һәм Аның Сүзе турында ешрак сөйләсәгез, сезнең көннәрегез күп тапкырга яхшырак үтәчәк. Ул сүзләрне үзегезне Ходай мәхәббәте белән бөтен яктан уралып алганызыны аңлап, уйлап әйтегез. Изге Язмада: «Ходай сезнең сурәтегезне Үзенең уч төбенә ясап куйган», — дип язылган (Ишагыйя 49:16-ны карагыз). Мин моны болай итеп күз алдыма китерәм. Ходай болай дип әйтә торгандыр: «Менә, карагыз әле. Күрәсезме? Ул бит

шундый искитәрлек. Мин аны бик нык яратам! Ул минем балам, ул минем уч төбемдә». Ходай, мәңгелек мәхәббәтенең билгесе итеп, сине Үзенең уч төбенә ясап куйган. Башыңа сыйдыра аласыңмы: Ул шулкадәр нык синең белән сөйләшергә, аралашырга тели (бик нык тели).

Ходайга рәхмәтле булыгыз һәм Аның белән күбрәк сөйләшегез. Аны күбрәк белү өчен, Аңа рәхмәтегезне әйтү өчен, Аның шулхәтле яхшы икәнен Аңа әйтү өчен, вакыты-вакыты белән эшләрегезне туктатып торыгыз. Ходайны яратыгыз. «Ходай Ул мәхәббәт. Яраткан кеше Ходайда, һәм Ходай анда. Шулай итеп (Аның белән сөйләшеп һәм килешүдә булып) бездәге мәхәббәт камилләшә һәм без хөкем көнендә нык булырбыз (ышанычыбыз нык булыр) (1-нче Яхъя 4:16–17, КТ). Ходайның сине яратуы турында белүең һәм аңлавың Ходайга күбрәк ышанырга, Аңа таянырга мөмкинлек бирә. Ходайга сине яратырга рөхсәт ит һәм син Аның фатихасын кабул итеп алырсың: ныклы иман, гөнаһны җиңу, күңел тынычлыгы, савыгу, сәламәтлек, Аның бүләкләре, куаныч-шатлык.

«Мин Ходайны яратырга тиеш», — дип уйлыйбыз без. Ләкин, минемчә, без башта Ходайның безне яратуына ышанырга һәм төшенергә тиешбез. Минемчә, Ходайның сезне яратуына ышанмыйча торып, сез Ходайга яратуыгызны җиткерә алмаячаксыз. Изге Язмада: «Ул безне башта яратканга күрә без Аны яратабыз», — дип язылган (1-нче Яхъя 4:19).

Әгәр дә без Ходайның безне яратуына ышанабыз һәм моны анлыйбыз икән, без, җавап итеп, Аны яратырга, Аның белән мөнәсәбәттә булырга сәләтле. Ходай белән ничек сөйләшергә белмисезме? Ходай мине Үзе белән сөйләшергә чакыргач, мин диванга утырдым да: «Ә хәзер нәрсә эшләргә, Ходай?», — дип сорадым. Әйе, әйе, чөнки ул вакытта Аллаһының мине ни кадәр көчле яратуын анламый идем, Аның белән сөйләшә белми идем. Мин шулай ук Аның минем тугрылыклы дустым һәм һәрвакыт минем белән булачак юлдашчым булырга теләве турында да белми идем. Ходай белән күбрәк вакыт уздырган саен, дога кылып, Аның Сүзен укып, Аның хозурында тынычланып, бер сүз дә дәшмичә

утырып, мин Аның белән сөйләшүдән ләззәтләнергә өйрәндем.

Ходайга таба бер адым ясагыз. Үзегез белән сөйләшергә Ходайга мөмкинлек бирегез. Ничек Ходай белән сөйләшергә өйрәнергә? Мин сезгә әзер формула бирә алмыйм, мин андый формуланы белмим. Ходай белән әңгәмәне берничә пункттан торган схема буенча төзүегезне бер дә теләмәс идем мин. Минем теләк: Ходай белән сөйләшергә сезне Изге Рух өйрәтсен иде. Шуңа күрә Изге Рухның җитәкчелегенә бирелегез. Ходай Үзе белән сезгә бик рәхәт булуын тели, чөнки, Эфеслеләргә 3:17-дә язылганча, сезнең күңелегез — Мәсихнең яшәү урыны.

# Мәхәббәт, ышанып тапшыру һәм иман

*«Әгәр дә без Гайсә Мәсихтә икәнбез, ул вакытта сөннәтле булу, яки сөннәтсезлек бернинди дә мәгънәгә ия түгел, ә бары тик мәхәббәт белән уяна торган иман, мәхәббәт белән хәрәкәт итә һәм күренә башлый».*

Гәләтиялеләргә 5:6, КТ

Безнең күпчелегебез иманлы булырга тырыша. Иманнан башка Ходайга ярап булмавы турында без беләбез (Гыйбриләргә 11:6), шуңа күрә, бөтен көчебезне куеп, без иманыбызны үстерергә тырышабыз. Ләкин, иман йөрәктән

чыга, Аның безне яратуы турында белүебездән, Аның белән сөйләшүдән, «Ходай сүзен ишетүдән» туа (Римлыларга 10:17). Шулай ук иман Ходайдан килгән ачылыштан. Мин сезне иманга өйрәтә алмыйм, ләкин мин сезне иман принципларына өйрәтә алам. Иманлы булу өчен сез бөтен мөмкин булган нәрсәләрне эшләсен өчен, мин сездә көчле теләк тудыра алам. Ходайдан сораганнарны кабул итеп ала торган кул — ул иман.

Без иманлы булырга тырышып, Ходайга ошарга тырышып, вакытны дөрес кулланмыйбыз — вакытны Ходай белән сойләшүгә багышларга кирәк. Аның мәхәббәтен кабул итәргә һәм, җавап итеп, безгә Аны яратырга кирәк. 1-нче Көринтлеләргә 5:7-дә болай диелгән: «Без тышкы күренеш белән генә түгел, тышкы яктан күренеп тора торган нәрсәләр белән түгел, ә иман белән хәрәкәт итәбез (тормышыбызны һәм тәртибебезне үзебезнең иман буенча төзибез, ә безнең ышанычыбызга һәм Аңа якынрак булуга омтылуга нигезләнгән Ходай белән булган мөнәсәбәтләребездә шикләнмибез)» (КТ).

Бервакыт, бу аятьне укыганда, Ходай миңа аңлатты: иман белән яшәргә теләвем, минем тырышуларым мине иманга алып килә алмый. «Әгәр дә мин Ходай белән булган мөнәсәбәтләремдә шикләнмәсәм, мин иман белән яшәргә сәләтле», — дип язылган бу аятьтә. Бу турыда фикер йөртергә кирәк. Үзегезгә шундый сорау бирегез: Ходай белән булган мөнәсәбәтләрегездән сез ни дәрәҗәдә канәгать?

Ходай каршында үзенең тәкъва икәнен танымаган кешенең иманы ныклы була алмый. Без Мәсихнең корбан булуы аркылы тәкъва (Көринтлеләргә 5:21). Безнең тәкъвалык без эшләгән яки эшләячәк гамәлләргә нигезләнми. Тәкъвалык Гайсә безнең өчен кылган гамәлгә нигезләнә. Үзен кызганыч, бәхетсез кеше дип санаган һәм Ходай яратуына ышанмаган кешенең иманы бик кечкенә була.

Гәләтиялеләргә 5:6-да: «Иман мәхәббәт белән хәрәкәт итә», — дип язылган. Күп мәсихчеләр: «Әгәр дә мин кешеләрне яратсам, минем иманым көчле булыр һәм мин Ходайдан сораган һәр нәрсәне Ходай миңа бирер», — дип уйлыйлар.

Әлбәттә, Ходай безнең кешеләргә карата мәхәббәтле булуыбызны тели. Ләкин, Ходайның безне яратуына ышанмыйча торып, без кешеләрне ярата алмыйбыз. Бик яхшы анлашыла: үзеңдә булмаган әйберне бүтән кешегә биреп булмый. Күп еллар буе мин кешеләрне яратырга тырыштым, чөнки Ходай безгә шундый әмер биргән һәм безгә ул әмерне үтәргә кирәк. Әмма дә ләкин, Ходайның мине бернәрсәгә карамыйча яратуын аңламыйча торып, мин кешеләрне ярата алмадым. Ходайның мине яратуына ышануым ныгыган саен, кешеләрне ныграк ярата алдым.

Әгәр дә Ходайның сезне яратуы турында беләсез икән, Ходайдан сораган әйберләрне җиңелрәк кабул итеп ала алырсыз. Ходайның яратуына, фатихаларга теләвенә, бөтен кирәк әйберләрне бирергә теләвенә күп кеше ышанмый. Ышанмаганга күрә, тормышта кирәк әйберләрнең булуын күрмиләр. «Мин ышанырга бик телим, ләкин ничек ышанырга соң?» — дип сорарсың. Ходайның мәхәббәте синең күңелеңдә, шуңа күрә сиңа бары тик моның шулай икәнен танырга һәм ул мәхәббәтнең тышкы хәрәкәтен күрә башларга

гына кирәк. «Ходайны яратыйк, чөнки ул безне алданрак яратты» (1-нче Яхъя 4:19). Әгәр дә Ходайның сине беренче булып яратканын белмәгән булсаң, Ходайны ярата алыр идеңме икән? Ходайның мәхәббәте безнең йөрәктә, күңел түрендә яши. Үзеңә Ходайның күзләре белән карый башлагач, моның шулай икәненә төшенерсең. Син шундый яхшы, сәләтле, кадерле — Ходай сине шундый итеп күрә. Ул сине ярата. Җир йөзендә башка берәү дә сине шул хәтле нык ярата алмаячак. Ходайның сине яратуы турында кубрәк уйлаган саен, син моның шулай икәненә ныграк ышаначаксың һәм тормышың тизрәк Ул синең өчен планлаштырганча була башлаячак.

Безгә Ходай Үзе генә дә җиткән булыр иде, ләкин Ул безнең тормышыбызга башка кешеләрне алып килә. Тормышыгызда Ходайдан башка берәү дә булмаган очракта да, сез үзегезне бик яхшы хис итәр идегез. Ходай сезнең иң яхшы дустыгыз булачак. Әгәр сез ялгыз икән, Ул сезнең тормыш иптәшегез урынына булыр. Әти-әниегез юк икән, Ул сезнең өчен әти һәм әни булыр. Сезгә кирәк булган бөтен

нәрсә — Ул. Ходайдан я тегене, я моны гына сорап, хата җибәрмәгез, тормышыгызны күбрәк Үзе белән тутыруын сорагыз. Ходайдан бөтен тормышыгызны Үзе белән тутыруын сорагыз (Эфеслеләргә 3:16,19).

Ходай сине ярата. Ул сиңа бөтен кирәкле әйберләрне бирергә тели, күңелең теләгән нәрсәләрне тормышка ашырырга тели. Әгәр дә Ходайның сине яратуына ышанасың икән, моның шулай икәнен аңлау сиңа куаныч алып килер, һәм үз вакытында Ул сиңа бөтен кирәк әйберне бирер (Зәбур 36:4). Ходай Тәгалә Ибраһимны фатихалавы һәм аны күп халыклар өчен фатиха итүе турында әйтә. Ходай синең өчен дә шулай эшләргә тели, ләкин син моңа ышанырга тиеш. Иманыгызны күрсәтегез: Ходайның бөтен вәгъдәләренә ышаныгыз, чөнки ул вәгъдәләрнең бөтенесе дә — сезнең өчен.

## *Иман һәм эшләр*

Эфеслеләргә 2:8-дә язылган: «Сез мәрхәмәт аркылы котылдыгыз… (Ходайның шәфкате

беләп, лаек булмаган шәфкать беләп)» (КТ). Аңлыйсызмы, котылу өчен сез бернәрсә дә эшләмәдегез! Гайсәне кабул иткәнгә кадәр, без гөнаһлы идек. Аның коткару бүләге, әлбәттә, безнең яхшы яки дөрес эшләребезгә нигезләнмәгән. Без котылуны бары тик бер сәбәп аркылы гына кабул итеп алабыз: «Ходай безне шулкадәр яратты ки, Углына иман итүчеләрнең берсе дә һәлак булмасын, ә мәңгелек тормыш алсын өчен, Үзенең бердәнбер Углын бирде» (Яхъя 3:16).

Мәрхәмәтне шулай итеп аңлатырга була: безгә кирәкле булган бөтен нәрсәне бирү өчен, Ходай безнең тормышыбызда Үзенең көч-куәтен кулланырга тели. Сез котылуны кабул итеп алсын өчен, Үзенең мәрхәмәте аркылы безгә иман бирә. Ходай сезнең теләкләрегезне үтәячәк һәм тормышыгызда кирәк нәрсәләрне бирәчәк — Ул сезгә моның шулай икәненә ышану бирә! Чөнки Ул сезне ярата. Сез, бәлки, якыннарыгызның котылуын телисездер, ләкин сез аларны мәҗбүр итә алмыйсыз. Алар Гайсәне кабул итсен дип, сез Ходайга дога кыла аласыз, ләкин үзегезнең гамәлләрегез белән кешеләрне коткара алмыйсыз.

Ходай Тәгалә генә эшли ала торган эшләрне үз көчебез белән эшләргә тырышу, ягъни гөнаһлы табигать эшләре — һәрвакыт өметсезлеккә генә алып килә. Без тырышып-тырышып карыйбыз да, яхшы нәтиҗәләргә килә алмыйбыз. Безгә Ходай алында баш иярга һәм Аннан ярдәм сорарга кирәк. «Ходай горурларга каршы тора, андыйлар Ходайны борчыйлар, Ходай аларга җиңелү бирә. Ә баш иючеләргә Ул мәрхәмәтен яудыра (шәфкатен, фатихасын)» (1-нче Петер 5:5, КТ).

Ходайның мәрхәмәте безнең тормышта бик мөһим урын алып тора. Без иман аркылы мәрхәмәт белән коткарылдык, шулай ук, һәр көнебезне иман аркылы мәрхәмәт белән яшәргә тиешбез. Әгәр дә Ходайның сезне яратуына ышанасыз икән, чынлап та Ходайга таяна аласыз. Ходай һәрвакыт вәгъдә иткәнен үти, шуңа күрә сез күзегез күргән белән түгел, ә иман белән яшәргә тиешсез.

Изге Язманың киңәйтелгән тәрҗемәсендә (Гәләтиялеләргә 1:4) болай диелгән: «Иман ул — бөтен килеш Ходайга таяну, Аның кодрәтенә,

зирәклегенә һәм мәрхәмәтенә камил рәвештә ышану». Әгәр дә Ходайның сезне яратуына ышанасыз икән, сез Аңа таяна алачаксыз, Аның кодрәтенә, зирәклегенә һәм мәрхәмәтенә ышана алачаксыз. Ходай белән мөнәсәбәтләрегез ныграк булган саен, иманыгыз да көчлерәк булачак. Ходай сезнең эчке дөньягызда, сезнең өчен һәм сезнең аша бөек нәрсәләр кылыр. Ләкин аңынчы Ходайның сезгә карата булган мәхәббәтенә ныгытып ышанырга тиешсез. Ул сезне чынлап та ярата — беркайчан да моның шулай икәнлегенә шикләнмәгез!

# Куркудан ирекле булу

*«Мәхәббәттә курку юк (курку гел юк, куркуның эзе дә юк), тулысынча үсеп җиткән (камил, бөтен нәрсәне каплап ала торган) мәхәббәт куркуны ишекнең теге ягына куып чыгара һәм куркуның хәтта эзе дә калмый. Курку үзе белән җәза турындагы уйлар алып килә, шуңа күрә курка торган кеше мәхәббәттә камиллеккә ирешмәгән (курка торган кеше камил мәхәббәткә тикле үсеп җитмәгән, аның яратуы камиллеккә ирешмәгән, камиллеккә тикле үсеп җитмәгән)».*

1-нче Яхъя 4:18, КТ

Кайвакыт шулай да була: безнең иман белән барсы да яхшы, без Ходайга таянабыз, Аның безне яратуына ышанабыз, шулай бервакыт безнең тормышыбызда ниндидер кыенлык яки начар хәл килеп чыга. Бик ук яхшы булмаган хәлләр безнең иманыбызны бөтен нәрсәгә караганда да ныграк сыный. Кайсыбер кешеләр Ходайның мәхәббәтенә ышана, ләкин, берәр нәрсә килеп чыгу белән, шикләнә башлыйлар. Шул вакытта дошман курку алып килә, безгә ярдәм итәргә мөмкинлеге булган Ходайның мәхәббәтеннән безне аеру өчен, үз-үзебезне гаепләргә мәҗбүр итә. «Ничек хәлләр», — дип, явыз итеп көлә башлый ул. «Ә мин Ходай сине ярата дип уйлаган идем, ә синең проблемаларың шундый күп. Берәр начар эш эшләгәнсеңдер һәм Ходай сиңа ачулана торгандыр».

Кыен вакытларда, сынау вакытларында, безгә карата гаделсезлек кылалар кебек тоелганда, Ходайга таянычыбызны бик җиңел югалтабыз. «Ходай эшләргә тиешле эшләрен башкарып җиткерми һәм дөрес вакытта башкармый», — дип уйлыйбыз без. Ә бит Аның планнары безнең

планнардан күп тапкырга яхшырак. Безнең тирә яктагы хәлләрне үзгәртүгә караганда, Ул ныграк безне үзгәртергә тели. Безнең Аңа ышанычыбыз ныгысын өчен, һәм без бары тик Аңа гына бөтен килеш таянырга өйрәнсен өчен, ешь кына Ул бик авырттыра торган хәлләрне куллана. Авыр очракларның ни өчен килеп чыкканын аңламаганда: «Ходай безне яратмый», — дип уйлый башлыйбыз. Шундый вакытларда безгә Римлыларга 8:35 – 39 — ны искә төшерергә кирәк: «Бер нәрсә дә безне Ходайның мәхәббәтеннән аера алмый, без һәммә нәрсәне үзебезне Яратучының көче белән җиңеп чыга алабыз», — дип язылган. Тормышыбызда кыен хәлләр башланганда зарлану сүзләре урынына, ишетерлек итеп, менә бу сүзләрне әйтегез: «Ходаем, Син мине яратасың һәм Син бу хәлне минем өчен бары тик яхшылыкка гына әйләндерәсең».

Кайвакыт Ходай безне авыр хәлләрдән арындырырга ашыкмый һәм без: «Инде соң», — дип уйларга мөмкинбез. Лазарны исегезгә төшерегез. Ул авырый, ә Гайсә Лазар янына ул үлгәннән соң гына килә. Марта Гайсәгә: «Син бик соң

килдең», — дип әйтә. Ләкин Гайсә нәрсә эшләвен һәм кайчан эшләвен бик яхшы белә: Ходайны данлар өчен, Ул Лазарны үледән терелтә. Ходай Үз эшләрен безнең расписание буенча эшләми, ләкин Ул беркайчан да соңга калмый. Тормышыгызда авыр хәлләр килеп чыкканда, Ходайдан күзегезне алмагыз һәм ышанугызны туктатмагыз. Курку һәм буталчык уйлар сезне Ходайның сезгә карата булган мәхәббәтеннән мәхрүм итмәсен.

1-нче Яхъя 4:18 — мәгънәсе буенча бик көчле аять: «…камил мәхәббәт куркуны куып жибәрә…» Бу сүзләрне яхшырак аңлау өчен, бик озак уйланып йөрдем. Бервакыт ут белән яктырткандай булды: камил мәхәббәт теләсә нинди куркуны куып җибәрә! Ә камил мәхәббәт ул — Ходай! Ходайның сине камил мәхәббәт белән яратуына ышансаң, курку сине параличка калдыра алмаячак. Бәлки, кайсыбер очракларда куркып калырсың, ләкин син ул куркуны җиңә алачаксың, чөнки Ходайның һәрвакыт синең белән икәнен беләсең.

Син уңышсызлыктан курыкмаячаксың, чөнки Ходайның сине нык яратуын беләсең. Син, әлбәттә,

теге яки бу эштә уңышка ирешергә тырышып карый аласың. Ходайның сиңа карата булган мәхәббәте синең уңышка ирешүеңнән яки ирешмәвеңнән тормый. Әгәр дә син Ходайга таянасың икән, уңышсызлыклар булмаячак. Үз көчегезгә таянган очракта гына унышсызлыклар булырга мөмкин. Тирә яктагы хәлләр, бәлки, син планлаштырганча килеп тә чыкмас, ләкин син күзеңне Ходайдан алмасаң, һәммә нәрсә синең өчен яхшы якка борылачак. Әгәр дә син Ходайның яратуы турында шикләнмисең икән, унышсызлыклар каршында, берәрсенең сине кире кагуы, берәр нәрсәнең җитешеп бетмәве, яки үткән тормыш каршында, яки киләчәк алдында, яки бүтән нәрсә алдында синең бернинди дә курку хисе булмаячак.

Ходайның мәхәббәте шундый бөек, ул сине башыңнан ук, бөтен килеш каплап ала. Сине коткарган һәм ирекка чыгарган Ходай синең унышсызлыкка эләгүеңә ирек куяр дип уйлыйсыңмы? Ул сине бер ярдәмсез калдырыр дип уйлыйсыңмы? Шайтан — безнең җаныбызның дошманы. Ул угры һәм ялганчы. Ә Гайсә мул

тормыш белән яшәвебезне тели, тормыштан ләззәт табып яшәвебезне тели.

Без инде бу сүзләрне укыдык: «Мәхәббәттә курку юк (курку гел юк, куркуның эзе дә юк), тулысынча үсеп җиткән (камил, бөтен нәрсәне каплап ала торган) мәхәббәт куркуны ишекнең теге ягына куып чыгара һәм куркуның хәтта эзе дә калмый. Курку үзе белән җәза турындагы уйлар алып килә, шуңа күрә курка торган кеше мәхәббәттә камиллеккә ирешмәгән (курка торган кеше камил мәхәббәткә тикле үсеп җитмәгән, аның яратуы камиллеккә ирешмәгән, камиллеккә тикле үсеп җитмәгән)» (1-нче Яхъя 4:18, КТ). Ходай миңа бу сүзләрнең мәгънәсен ныграк аңларга ярдәм иткәннән соң күп тә үтмәде, үз тормышымда аларны сынарга туры килде. Безнең машина белән кыенлык килеп чыкты. Коробка передач начар эшли башлады, ә безнең аны яңага алыштырырга акча юк иде. «Ватылмаса ярар иде», — дип өмет итеп, машина белән йөрүебезне дәвам иттек.

Шулай бер көнне, иртә белән, Ходай миңа болай диде: «Джойс, бүгенге көнеңне мине яра-

туга багышла һәм Миңа сине яратырга мөмкинлек бир. Сиңа бүтән бер нәрсә дә эшләргә кирәк түгел. Бөек иманлы кеше булырга тырышма. Бары тик минем мәхәббәтемдә бул — Мин синнән бүген бары тик шуны гына сорыйм». Шуңа күрә мин көн буе Ходайга җырлар җырладым, вакытны бик яхшы итеп уздырдым. Көтмәгәндә гаражда иремнең тавышы ишетелде, бер сәгать элек ул эшкә киткән иде: «Мин беренче тизлектән башкага күчерә алмадым. Машинаны гаражда калдырырга, ремонтларга туры килер», — диде ул ишекне ачып.

Мин көлеп җибәрдем. Гадәттә, андый очракларда, мин көлмим. Ул вакытта да мин көлергә җыенмаган идем. Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты. Көне буе Ходайның яратуына игътибар биргәнгә, көне буе шул мәхәбәттә булганга күрә, кыен вакытта да мин шатлык белән тулы идем. Ходайның мәхәббәте белән ләззәтләндем, һәм ул мәхәббәт минем иманга юл ачты, ә куркуга юлны ябып куйды. Минем көлүем иманымның тышкы күренеше иде. Ходай безне ярата һәм бөтен кирәк әйберне Ул безгә бирәчәк — мин

моның шулай икәнен эчемнән белә идем, шуңа күрә көлдем дә.

Ходай Ибраһимга: «Синең улың булачак», — дип әйткәч, ул да көлеп җибәргән. Аның көлүе дә иман билгесе булган. Сара белән үзенең инде бала таба алырлык яшьтә түгел икәнен аңлаганга күрә, шуңа карамастан ышанып, ул шатлыгыннан көлеп җибәргән.

Кыенлыкларга шулай итеп караганда, Ходайга үзебезгә искиткеч рәвештә ярдәм итәргә мөмкинлек бирәбез. Кыенлыклар булганда кемнең көләсе килеп тора? Ә менә Изге Язмада: «Ходай күкләрдә дошманнарыннан көлеп утыра», — дип язылган (Зәбур 2:2–4). Ходай шулай эшли икән, безгә дә шулай эшләргә кирәк. Шатлан! Синең шатлык иманыңның билгесе булсын. Һәрвакыт исеңдә тот: Ходай сине ярата! Ходай синең яклы икән, кем сиңа каршы була ала?

# Мәхәббәт бирә

*«Бу әмер (күрсәтмә, боерык, бурыч) безгә Ходайдан: Ходайны яратучы якынын да яратырга тиеш».*

1-нче Яхъя 4:21, КТ

Син Ходайның үзенчәлекле баласы. Син уникаль, синең кебек кеше бүтән юк (Канун 7:6). Әгәр син Ходайның сиңа булган мәхәббәтен беләсең икән, шушы белем сиңа куаныч һәм ныклылык хисе өсти икән, дөньяга булган карашың да үзгәрәчәк. «Ходай мине ярата. Минем бөтен нәрсәм дә бик шәп. Мин кешеләргә Ходайның мәхәббәтен бүләк итә алам», — дигән уйдан сез ешрак елмаячаксыз. Кайда гына булсагыз да, сез бәхетле булачаксыз, һәм сезнең шатлык башка кешеләргә дә күчәчәк. 99:2-нче Зәбурда: «Ходайга шатланып хезмәт итегез», — дип язылган.

Ходай өчен үзебезнең бик кадерле икәнебезне аңлаган очракта, бу аңлау кешеләргә карата булган мөнәсәбәтебездә һәм гамәлләребездә дә күренеп торачак. Без кешеләргә Мәсих турында сөйләргә сәләтле булачакбыз, шаһитлыгыбыз кешеләрнең игътибарын Мәсихкә җәлеп итә алачак. Сезне бөтен килеш тутыра торган Ходайның мәхәббәте кешеләрнең мохтажлыкларына игътибарлы булырга өйрәтер, кешеләргә карата кызгану хисе уятыр. Күңелегездәге Ходайның мәхәббәте сезне куркудан ирекле итәр, һәм сез кешеләрне яратырга курыкмассыз. Кире кагу, яки берәрсенең сезне кулланырга теләве сезне куркытмас. Ходайның мәхәббәте кешеләрнең мохтаҗлыкларына сезнең күзләрегезне ачар һәм сез аларга ярдәм итә алырсыз.

Ходай Тәгалә сезнең аша искитәрлек эшләр кылырга тели, чөнки сездә Гайсә яши — Ул моңа ышануыгызны тели. Ходайга таяныгыз: Ул сезнең аша хәрәкәт итәргә, сезнең аркылы кешеләргә ярдәм итәргә, кешеләргә Үзенең мәхәббәтен күрсәтергә тели. Ходайның камил мәхәббәте куркуны куып җибәрә, шуңа күрә

куркуга иман адымнарын ясарга комачауларга рөхсәт бирмәгез.

Мин ничәмә-ничә тапкыр искиткеч эшләр алдында куркып, туктап калдым, ләкин Ходай мине ныгытты: «Джойс, әйдә. Мин синең аркылы бөек эшләр эшләячәкмен. Әйдә, алга!» — диде. Иман белән атлаган һәр адымымда Ходай минем янымда булды. Ни өчен курыкмыйча иман белән атлавымны беләсезме? Чөнки Ходайның мине яратуына бер дә шикләнмим. Ул мине ярата һәм минем дә аны яратуымны белә. Ходайның мәрхәмәте белән, мин үземнең тормышымны, гомеремне Аның аяклары астына салдым. Әгәр дә сез Ходайны яратасыз икән һәм Аның сезне яратуын беләсез икән, сез теләсә нинди авырлыкны хәл итә аласыз.

Әгәр дә сез чыннан да кешеләргә ярдәм итәргә теләсәгез, Ходай сезгә ярдәм итәчәк. Моның өчен сезгә бик сәләтле булырга яки унайлы очрак эзләргә кирәк түгел. Үзегезне Ходайга тапшырыгыз һәм бөтен калган эшне Ул Үзе эшләячәк. Сез бәлки: «Мин гади кеше, минем сәләтләрем бик юк», — дип әйтерсез. Ә Ходай

нәкъ менә гади кешеләр аркылы иң бөек, кодрәтле эшләрне башкара да инде.

Үз-үзегезне генә ярата торган кеше булмагыз — тормышыгызны үзегез өчен генә, үзегезнең кирәк-ярakларыгызны булдыру өчен, үзегезнең теләкләрегез өчен генә кулланмагыз. Үзегезгә кирәк нәрсәләр турында Ходайга әйтегез, үзегезнең теләкләрегезне Аңа ачыгыз, ә соңыннан, Изге Рух сезне башка кешеләргә ярдәм итәргә юнәлткәндә, бик игътибарлы булыгыз. Сез башкаларга ярдәм итсәгез, Ходай сезгә ярдәм итә. Әгәр сезнең берәр мохтаҗлыгыгыз бар икән, орлык чәчегез — башка бер кешегә аның мохтаҗлыгын хәл итәргә ярдәм итегез, ә Ходай сез чәчкән шул орлыкны үстерер, орлык үсеп, күп җимеш китерер.

Һәр кеше уңышлы булырга тели. Ләкин без чынлап та уңышлы булуның нәрсә икәнен аңларга тиешбез. Мин шулай дип әйтер идем: кемнеңдер мохтаҗлыгын бөтен килеш каплау, кешегә ярдәм итү — уңыш. Ходайның мәхәббәте сезгә башка кешеләрнең мохтаҗлыкларын үзегезнекеннән өстенрәк куярга ярдәм итәр.

Кайсыбер кешеләргә ярдәм итәсе килми, кайбер кешеләр зарланучан, рәхмәтсез — Ходай сезгә андый кешеләрне дә яратырга ярдәм итәр.

Сезне яртакан кешене яратырга сезгә кыен түгел, хаттә моның өчен тырышып та торырга кирәк түгел. Ә менә сезнеңчә мәхәббәткә лаек булмаган кешеләрне ярату өчен Ходайның мәрхәмәте кирәк. Ходайның мәхәббәтендә сез андый кешеләрне дә ярата аласыз, чөнки Аның мәхәббәте шартсыз. Без ул мәхәббәтне бушлай кабул итеп алабыз һәм бушлай таратырга тиеш. Андый мәхәббәт беркайчан да юкка чыкмый һәм бирәүгә дә кул селтәми. Бәлки, андый кешеләрне ярата башлау өчен сезгә бер ел, биш ел, яки егерме ел кирәк булыр — барыбер шундый яратуга омтылырга кирәк. Әгәр дә сезнең кайсыбер кешеләргә карата түземлегегез җитми икән, исегезгә төшерегез — Ходай сезне сез яхшы якка үзгәргәнчегә кадәр яратты. 1 Көринтлеләргә 13-нче бүлектә язылган: «Мәхәббәт озак түзүчән, игелекле һәм күркәм, мин-минле түгел һәм үпкәләми». Гайсә безне шулай ярата. Без дә үзебезне кимсетә торган кешеләргә шундый

мәххәббәтне күрсәтә алабыз. Алар бәлки, үзләре дә аңламыйча, Ходайның мәхәббәтенә сусаганнардыр.

Ходай сезне дә ярата, сезнең тирә ягыгыздагы кешеләрне дә ярата. Алар гөнаһлы булсалар да, Ходай аларны ярата һәм нәкъ менә сезнең аркылы аларга Үзенең мәхәббәтен бүләк итәргә тели. Тирә ягыгыздагы кешеләргә таба адым ясарга курыкмагыз. Ходай сезгә ярату сәләте биргән, мәхәббәт сезне куркудан һәм үз-үзегезне гаепләүдән ирекле итәр. Ходайның мәхәббәтен кешеләргә кыю рәвештә таратыгыз. Ә башта яныгыздагы кешеләргә яхшы мөнәсәбәт күрсәтә башлагыз. Кайда гына булсагыз да, кешеләргә куаныч таратыгыз. Кунакчыллык — яратуны курсәтә торган бик яхшы ысул — бигрәк тә, әгәр кеше ялгыз булса, яки кәефсез яки борчылган вакыты булса. Кичке ашка чакырыгыз. Кешеләрне кунакка чакырыгыз. Кул биреп исәнләшегез, елмаегыз, кочаклагыз, күңелләрен күтәрә торган сүзләр әйтегез, ярдәм итегез. Мисал өчен, эшләгән урыныгызда эшкә яңа кеше урнашса: «Ярдәм кирәк тугелме», — дип сорагыз.

Ходайның сезгә эше бар. Бәлки сезгә Ул кушкан эшләр бик мөһим яки зур кебек тоелмас, ләкин Ходай өчен ул эшләр бик мөһим. Ходай өчен кеше бик мөһим. Кайсыбер кешеләргә бары тик син генә ярдәм итә аласың. Ходайдан сорагыз: кешеләргә Аның мәхәббәтен ничек күрсәтергә? Һәм Ул сине яратырга өйрәтер.

# Ходайның мәхәббәте сине үзгәртер

*«Мәхәббәт шунда ки, без Ходайны түгел, ә Ул безне яратты һәм, мәрхәмәтен күрсәтеп (мәрхәмәте белән), безнең гөнаһлар өчен (коткара торган корбан итеп) Үзенең Улын җибәрде».*

1-нче Яхъя 4:10, КТ

Ходай безне ярата, ләкин, минемчә, күпчелек кеше ул мәхәббәтнең ни дәрәҗәдә бөек һәм көчле икәнен аңлап бетерми. Мин Ходайның мәхәббәте турында өйрәнгәндә, Ходай Тәгалә

аңларга ярдәм итте: Ходайның безне бик нык яратуы турында белгән очракта без үзгәрәбез һәм гел икенче төрле эшләр эшлибез.

Ходайның сине яратуы турында уйлап йөр. Фикер йөрт һәм син үзгәрәчәксең. Әгәр сиңа үзеңдә берәр нәрсә ошамый икән, Ходайның сине яратуына ышану сиңа үзгәрергә ярдәм итә, ә менә үз-үзеңне гаепләп, үзеңә кул селтәү — беркайчан да үзгәрергә ярдәм итмәячәк. Һәрвакыт исеңдә тот: Ходай иман аша хәрәкәт итә, иман Ходайның тынычлыгына керергә ярдәм итә (Гыйбриләргә 4-нче бүлек).

Үз-үзләрен яратмаган кешеләр шактый күп. Алар үзләрен яратмыйлар, ә кемдер хаттә үз-үзен күрә алмый. Әгәр син дә шундый кешеләр санына керәсең икән, мине ишет: син үзеңнең начар эшләреңне күрә алмаска мөмкинсең, ә үзеңә беркайчан да андый мөнәсәбәт булырга тиеш түгел. Сине бик нык ératканга күрә, Гайсә синең өчен үлгән. Ул Үзенең кыйммәтле бүләген синең кабул итеп алуыңны тели. «…Кешенең күңелендә нинди уйлар, кеше үзе дә шундый…» (Гыйбрәтле сүзләр 23:7). Әгәр дә син һәрвакыт

үзең белән канәгать түгел икәнсең, үзеңне кире кагасың икән, үзеңне кабул итмисең икән, үзеңнең кыйммәтле һәм уникаль икәнеңне танымыйсың икән, синең йөрәгеңдә һәм тормышыңда шатлык һәм тынычлык булмаячак, һәм бу синең холкыңда, эш-гамәлләреңдә күренеп торачак. Сәбәбе — Ходайның сине шуның хәтле нык яратуы турында син әле һаман белмисең.

Ходай Тәгалә көн саен синең белән сөйләшергә тели — бу сине шулай ук үзгәртәчәк. Әгәр дә син Ходайны беренче урынга куймыйсың икән, Ул синең өчен әзерләгән бөтен бүләкләрне сиңа бирү мөмкинлегеннән үзеңне мәхрүм итәсең. Ходайга яратуыңны күрсәтеп, Аның белән сөйләшергә вакытыңны аерып куй һәм Аңа сине яратырга мөмкинлек бир. Шул вакытта син көчле, кыю, бәхетле һәм рухи яктан өлгергән кешегә әйләнерсең.

Ходай белән мөнәсәбәт төзергә вакыт тапмаган кешеләр үз-үзләрен төрлечә аклыйлар. Алар Ходай белән ныклы мөнәсәбәттә булырга телиләр, ләкин Аның Сүзен өйрәнүдә һәм догада тырышырга теләмиләр. Әгәр син дә

шулай эшлисең икән, көн саен Аның белән вакыт уздыру гадәте барлыкка килсен дип дога кыл — чөнки бөтен эшләр арасында иң яхшы эш — Ходай белән булу.

Ходайның мәхәббәте сине үзгәртәчәк. Ходайның сине яратуы турында аңлагач һәм ул мәхәббәтне тоя башлагач, синең уй-теләкләрең үзгәрчәк, син Гайсәгә охшарга тырыша башлаячаксың. Үз-үзеңдә тәкъва холык булдыру һәм тагын да ныграк Аңа охшарга тырышу — иң мөһим максатларыңның берсенә әйләнергә тиеш. Паул барыннан да ныграк Мәсихне һәм Аның үледән терелү кодрәтен белергә теләве турында әйткән (Филиппуйлыларга 3:10).

Ходай белән булган мөнәсәбәтләреңә карата бик җитди кара — мин синнән бу турыда сорыйм. Ни кадәр телисең, шул дәрәҗәдә Ходай белән якын була аласың — бу Ходай белән күпме вакыт уздырырга әзер булуыңнан гына тора. Изге Язмада: «Без Ходайның вәкилләре һәм Ул дөньяга безнең аркылы мөрәҗәгать итә», — дип язылган (1 Көринтлеләргә 5:20). Бу аять һәрвакыт минем йөрәгемә кагыла. Ходай безне

Үзенең планы буенча үзгәртү өстендә эшләгән вакытта, безгә Изге Рухның әмерләре буенча хәрәкәт итүнең бик мөһим икәненә икенче төрле карарга ярдәм итә. «Ходайның мәхәббәте безгә Изге Рух белән коелган (Римлыларга 5:5). Бу сүзләргә ышаныгыз һәм Ходайның мәхәббәте белән ләззәтләнегез, үзегезне һәм сезнең тормышыгызны үзгәртергә рөхсәт итегез.

# Тәүбәгә килү догасы

Ходай сине ярата һәм синең Үзе белән якын һәм ныклы мөнәсәбәтләрдә булуыңны тели. Әгәр дә син әле Гайсә Мәсихне үзеңнең Раббың һәм Коткаручың итеп кабул итмәгән булсаң, хәзер кабул итә аласың. Ходайга Үзеңнең йөрәгеңне ач һәм шушы доганы кабатла:

*«Күктәге Әтием. Синең алдыңда гөнаһлы булуымны таныйм. Зинһар өчен, мине кичер, мине чистарт, тазарт. Мин Гайсәгә, Синең Углыңа иман китерәм. Ул минем гөнаһларым өчен үлгән — мин моңа ышанам. Хачта үлгәндә, Ул минем гөнаһларымны Үз өстенә алган. Гайсәнең үледән терелүенә ышанам. Мин Гайсәгә Үземнең тормышымны тапшырам. Атам, гөнаһларымны ярлыкавың һәм миңа мәңгелек тормышны бүләк иткәнең өчен рәхмәт Сиңа. Зинһар өчен, Синең өчен яшәргә ярдәм ит. Гайсә Мәсих исеме хакына, амин».*

Әгәр дә син бу доганы чын күңелеңнән кылсаң, Ходай сине кабул итте, чистартты һәм рухи үлем чылбырларыннан ирекккә чыгарды.

Бу аятьләрне укыгыз һәм өйрәнегез, Ходайның тавышын ишетүдә Аның ярдәмен сорагыз, чөнки хәзер сезнең өчен яңа тормыш башлана:

| | |
|---|---|
| Яхъя 3:16 | 1-нче Көринтлеләргә 15:3 – 4 |
| Эфеслеләргә 1:4 | Эфеслеләргә 2:8 – 9 |
| 1-нче Яхъя 1:9 | 1-нче Яхъя 4:14 – 15 |
| 1-нче Яхъя 5:1 | 1-нче Яхъя 5:12 – 13 |

Гайсә Мәсих турында күбрәк белү өчен, рухи яктан үсү өчен сезгә яхшы бердәмлек табарга кирәк. Ул бердәмлектә Ходайның сүзен бик яхшы итеп өйрәнү булырга тиеш. Шундый бердәмлекне табарга ярдәм сорап, Ходайга дога кылыгыз. Ул һәр көн саен сезгә юл күрсәтеп торыр, сезнең өчен Ул әзерләп куйган мул тормыш беләң яшәргә өйрәтер.

# Автор турында

ДЖОЙС МАЙЕР — дөньякүләм танылган шәхес, бөтен дөнья буенча Ходай Сүзен өйрәтүче мөгаллимә.

«Куаныч белән тулы тормыш», — дип аталган телевизион һәм радиопрограммасы бөтен дөнья буенча йөзләгән телевизион каналларда күрсәтелә һәм йөзләгән радиоканалларда чыга.

Джойс Майер 100-дән артык китап авторы. Аның китаплары арасында «Үзегезгә ярдәм итегез — кичерергә өйрәнегез», «Фикер көче», «Акыл — көрәш кыры», «Кол булу урынына матурлык», «Беркайчан да бирелмәгез» дигән китаплары бестселлерлар.

Ел саен Джойс дөньякүләм конференцияләр уздыра. Ул конференцияләрдә йөзләгән кеше катнаша.

Джойс Майер программаларын
дистәләгән телләрдә менә бу сайтта
карарга мөмкин

tv.joycemeyer.org

# Аллаһының сезне бик нык яратуы турында сез **чынлап та** беләсезме?

«Аллаһы сезне ярата!» — бәлки сез бу сүзләрне бик күп тапкырлар ишеткәнсездер. «Аллаһы дөньяны шулкадәр яратты ки...» һәм «Аллаһы — мәхәббәт Ул» — Изге Язмадагы бу сүзләрне кешеләр еш кабатлыйлар. Ә сорау менә нәрсәдә: Аллаһының сезне берсүзсез, һәрдаим, бернәрсәгә карамыйча яратуын сез чынлап та беләсезме? Бу хакыйкать сезнең көндәлек тормышыгызның бер өлешенә әйләндеме? Аллаһы сезне нинди итеп барлыкка китергән — шундый булырга курыкмыйсызмы? Ул сезнең өчен планлаштырган эшне тормышыгызда башкарасызмы?

**Классикага әйләнгән бу китап сезгә:**

- *Аллаһының мәхәббәте турында Изге Язмада язылган хакыйкатьне тагын да тирәнрәк төшенергә,*
- *Аллаһының мәхәббәтен кабул итеп ала белергә һәм башка кешеләргә дә бүләк итә белергә,*
- *бу хакыйкатьнең тормышыгызны көн саен үзгәртүен күрергә,*
- *Аллаһының мәхәббәтендә көн саен ничек яшәргә икәнлеген өйрәтер.*

Бу китап юлларындагы хәбәр Гайсә Мәсихкә иман итүче һәр кеше өчен. Аның белән якын, шәхсән мөнәсәбәтләр төзергә теләгән кешеләр өчен. Үзенә Аллаһы Тәгалә биргән потенциалын ачарга, тормышының төп эшен башкарырга теләгән кешеләр өчен. Сез инде күп еллар иман итүчеме, әллә күптән түгел генә иман китергән кешеме — ничек кенә булмасын, бу китапта язылган хакыйкать сезгә Аллаһыга якынрак булырга ярдәм итәр, чөнки сез Аллаһының бөек мәхәббәте турында тагын да күбрәк белерсез.